ГЛАВА
БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 ноябрь, 2019ел Олы Кайбыч авылы № 5

2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлаулары уздыру турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «2020 елга һәм 2021-2022 елларга план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты проекты турында»гы карар буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 13 ноябрендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында халыкка игълан ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының «2020 елга һәм 2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты проекты турында»гы карары буенча халык тыңлаулары уздырырга.
2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүматый стендларында һәм рәсми сайтында 2019 елның 23 нче ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Билгеләргә:

халык тыңлаулары уздыру вакыты – 30.11.2018 10.00 сәг;

уздыру срогы – 1 көн;

уздыру урыны – ТР, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7 нче йорт (иҗтимагый үзәк бинасының Актлар залы);

халык тыңлауларында фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, чыгыш ясап катнашуга гаризалар бирелергә мөмкин адрес: ТР, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар урамы, 7 нче йорт.( эш көннәрендә - 8.00 - 17.00 сәг кадәр).

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитетына 2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм уздырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин